СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

13.03.2015 с. Шеланга № 46-192

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен муниципаль районның җирле үзидарә органнарына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Советы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитетына Югары Ослан муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетларының вәкаләтләрен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

- дәүләт милке чикләнмәгән һәм тиешле авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир участоклары белән эш итү буенча.

2. Югары Ослан муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең вәкиллекле органнары тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында, Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге башкарма комитетына күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта:

Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү Шилангы хакында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең 2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар план чорына карар проектын эшләргә һәм карарга тәкъдим итәргә.

3. Авыл җирлеге мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Шилангы авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров